**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
18 ноября 2022

КАРАР
№ 145

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә түләү шартлары турында» гы Татарстан Республикасы Әтнә район Советының № 135 14.09.2022 елның карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 2 августындагы 751 номерлы карары нигезендә «Бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәт хакы шартлары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.03.2018 елның 195 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында», Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының аерым оешмалары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм аларның хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында, Әтнә район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 14.09.2022 ел, № 135 карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренә түләү шартлары турында"гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 2 пунктчасында «8» санын «10» саннары белән алыштырырга;

2) 5 пунктның 3 пунктчасында «бер» сүзеннән соң «айлык» сүзен өстәргә;

3) 5 пунктның 6 пунктчасындагы 3 абзацында «хезмәт законнары һәм башка норматив-хокукый актлар белән билгеләнгән» сүзләрен «сәгатьлек тариф ставкасының 7 проценты күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 8 пунктның 2 пунктчасында «сигездән бер айлык тариф ставкаларын» сүзләрен «бер бөтен уннан сигез айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

5) 8 пунктның 3 пунктчасында «айлык тариф ставкаларын» сүзләрен «айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

6) 9 пунктның 5 абзацында «карарлар» сүзен «карарлар» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И. Гыймадиевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Әтнә муниципаль районы башлыгы -**
**Әтнә район Советы рәисе** **Г. Г. Хәкимов**